ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.12, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет мәйданы, 12 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-00-44, факс (84366)3-11-44. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

# КАРАР

«17» ноябрь 2022 ел № 1024

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә пассажирлар транспорты маршрутларын тикшерү буенча комиссия төзү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы территориясендә пассажирлар транспорты маршрутларын тикшерү буенча комиссия төзергә һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы пассажир транспорты маршрутларын тикшерү комиссиясе составын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының пассажир транспорты маршрутларын тикшерү комиссиясе турында нигезләмәне 2 нче кушымта нигезендә расларга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының рәсми сайтына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеге башлыгы И.Ә. Кадыйровка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе Р.М.Гатиятов

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
_____________ ел, №__
карарына 1 нче кушымта

Арча муниципаль районы территориясендә пассажир транспорты маршрутларын тикшерү комиссиясе составы

| | |
|---|---|
| Гатиятов Р. М. | комиссия рәисе |
| Галимуллин И.Ә. | комиссия рәисе урынбасары; |
| Хәсәнов И.М. | комиссия секретаре |
| Гәрәев Р.Б. | пассажирлар ташучы (перевозчик) (килешү буенча); |
| Хуҗин Р.Р. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Арча районы буенча ЮХИДИ идарәсенең юл хәрәкәте иминлеге дәүләт инспекторы, полициянең өлкән лейтенанты (килешү буенча). |
| Сафиев А.Т. | Арча «Татавтодор» ҖЧҖ |
| Хәкимов А.Д. | «Жилкомбытсервис» ҖЧҖ |

Арча муниципаль районы
Башкарма комитетының
_____________ ел, №__
карарына 2 нче кушымта

## Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының пассажир транспорты маршрутларын тикшерү комиссиясе турында нигезләмә

### 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының автобус маршрутларын тикшерү комиссиясе (алга таба -комиссия) турында әлеге нигезләмә ( алга таба- Нигезләмә) гамәлдәге РФ законнары нигезендә эшләнгән һәм комиссияне формалаштыру, комиссия эшен оештыру, автобус маршрутларын тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибен билгели.

1.2. Комиссия РФ законнары белән Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы халыкка транспорт хезмәте күрсәтү өчен шартлар тудыру һәм гамәлдәге һәм яңа ачылган автобус маршрутларының иминлеген тикшереп тору өлкәсендә Башкарма комитет күрсәтмәләрен гамәлгә ашыруны тәэмин итүче эшче орган булып тора.

1.3. Комиссия үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының хокукый актларына, әлеге Нигезләмәгә таяна.

### 2. Комиссиянең максатлары, бурычлары һәм функцияләре

2.1. Комиссия Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының гамәлдәге һәм яңа ачылган автобус маршрутларын тикшерү өчен төзелә.

2.2. Комиссия үз вәкаләтләрен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы оешмалар, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының автомобиль юлларына хезмәт күрсәтүче предприятиеләр, хокук саклау органнары белән берлектә гамәлгә ашыра.

2.3. Комиссиянең төп бурычлары:

- автобус маршрутларында пассажирлар йөртүнең иминлеген арттыру;
- автомобиль юлларын, урамнарны, ясалма корылмаларны, тимер юл аша чыгу урыннарын, аларның инженерлык җиһазларының Россия Федерациясе дәүләт стандартларында, төзелеш нормаларында һәм кагыйдәләрендә, автомобиль юлларын ремонтлау һәм тотуның техник кагыйдәләрендә, башка норматив документларда билгеләнгән юл хәрәкәте иминлеге таләпләренә туры килүен тәэмин итү;
- автобус маршрутларында имин юл шартларын тәэмин итү һәм аларның үтәлешен тикшереп тору.

2.4. Комиссия үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге функцияләрне башкара:

- аларны ачу алдыннан һәм эксплуатацияләү барышында автобус маршрутларында юл шартларын тикшерүне гамәлгә ашыра - елга кимендә ике тапкыр (язгы чорда, көзге-кышкы чорда), шулай ук тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү белән юл шартларының куркынычсызлык таләпләренә туры килмәве турында мәгълүмат алган очракта, автобус маршрутларын файдалану мөмкинлеге турында Комиссия бәяләмәсе бирелгән әлеге Нигезләмәнең кушымтасы нигезендә форма буенча; автомобиль юлларын, урамнарны, ясалма корылмаларны, тимер юл аша чыгу урыннарын, аларның инженерлык җиһазларын карап тотуның техник халәтендә ачыкланган җитешсезлекләрне бетерүне тикшерә.

2.5. Автобус маршрутларының юл хәрәкәте иминлеге таләпләренә туры килүе түбәндәгеләр нигезендә билгеләнә:

- тикшерелә торган маршрутта пассажир ташучы тарафыннан бирелә торган автобус маршруты турында мәгълүмат;

- автобус маршрутында юл шартлары турындагы күрсәткечләр (параметрлар һәм юл өлешенең торышы, юл кырыйлары, юл планы һәм профильләре элементлары, хәрәкәт ешлыгы һәм составы, ясалма корылмаларның, тимер юл аша чыгу урыннарының торышы, хәрәкәтне оештыру чаралары һ.б.), юллар алар карамагында булган юл, коммуналь һәм башка оешмалар тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматлар;

- юл-транспорт һәлакәтләре еш була торган урыннар турында белешмәләр, аларның Дәүләт автомобиль инспекциясе органнары тарафыннан күрсәтелгән сәбәпләре; маршрут буенча тикшерү үткәрү барышында визуаль карау һәм инструментлар ярдәмендә үлчәүләр юлы белән турыдан-туры тикшерү.

## 3. Комиссия эшен оештыру

3.1. Комиссия эшен комиссия рәисе оештыра. Ул булмаган очракта, комиссия җитәкчелеге функцияләрен рәис урынбасары башкара.

3.2. Комиссия гамәлдәге һәм яңа ачылган автобус маршрутларын тикшерү өчен комиссия рәисе тарафыннан елына кимендә ике тапкыр (язгы-җәйге чорда, көзге-кышкы чорда) чакырыла.

3.3. Комиссия әгъзаларының гомуми саныннан кимендә 2/3 булса, комиссия карары тулы хокуклы була.

## 4. Автобус маршрутларын тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү тәртибе

4.1. Автобус маршрутларын тикшерү нәтиҗәләре гамәлдәге һәм яңа ачылган автобус маршрутларын эксплуатацияләү мөмкинлеге турында комиссия биргән акт белән рәсмиләштерелә. Алар иминлек таләпләренә туры килмәгән очракта, актта юл хәрәкәте шартларын яхшыртуга һәм автобус маршрутында юл-транспорт һәлакәтләрен кисәтүгә юнәлдерелгән

кичектергесез һәм перспектив чаралар уздыру турындагы тәкъдимнәр чагылдырыла.

4.2. Актларның күчермәләре алар карамагында юллар, урамнар, ясалма корылмалар, тимер юл аркылы чыгу урыннары, ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча кичектергесез чаралар үткәрү өчен инженерлык җиһазлары булган юл, коммуналь һәм башка оешмаларга җибәрелә. Актларның күчермәләре шулай ук күчмә составның юл шартларына туры килүен тәэмин итү, машина йөртүчеләрнең инструктажларын үткәрү өчен файдалану, куркыныч участокларның схемаларын төгәлләштерү, автобусларның хәрәкәт тизлеген нормалаштыру (төзәтү) өчен тикшерелә торган маршрутларда пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручыга тапшырыла.

4.3. Гамәлдәге автобус маршрутлары юл хәрәкәте иминлеге таләпләренә туры килмәгән очракта, автобус маршрутларын тикшерү комиссиясе бу автобус маршрутларында автобус хәрәкәтен вакытлыча туктату яки ябу турында карар кабул итә. Автобус хәрәкәтен туктату турындагы карар кабул ителгәннән соң шунда ук үз көченә керә, тиешле маршрутларда пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы халыкка (массакүләм мәгълүмат чаралары һәм тиешле маршрутлар тукталышларында эленеп торган игъланнар ярдәмендә) хәбәр итә.

4.4. Юл яки метеорологик шартлар пассажирлар ташу иминлегенә куркыныч тудырган очракларда, пассажирлар ташучылар, автовокзаллар һәм пассажир автостанцияләре, юл, коммуналь оешмалар, ЮХИДИ органнары үз вәкаләтләре нигезендә автобус хәрәкәтен туктатырга тиеш.

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының пассажир транспорты маршрутларын тикшерү комиссиясе турындагы нигезләмәгә кушымта

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районында
____________________________автомобиль юлы
маршрутны тикшерү акты

___________________ 20__ ел

| | Ачыкланган җитешсезлекләр, СПиПтан тайпылышлар | Юл өлеше урыны (километр, торак пункт) |
|---|---|---|
| 1. Юлның машиналар йөрү өлеше | | |
| 1.1 | Юлның машиналар йөрү өлеше өлешенең киңлеге юлның категориясенә туры килми (норма буенча: П категория - 9 м; III категория - 8 м; IV категория - 7 м) | |
| 1.2 | Юлның машиналар йөрү өлешенең торышы канәгатьләнерлек түгел: өслектә авария китереп чыгарырга мөмкин башка предметлар булу; өслектә ябылмаган ярыклар; тигезсезлекләр; 15 х 60 х 5 см дан да артык булмаган зарарланулар (чокырлар) булу; өслектәге битум ярылу; дулкыннар ясалу; өслек күчү; вак ташлы өслекнең тузанлануы | |
| П. Юл кырыйлары | | |
| 2.1 | Юл кырыйларының киңлеге һәр яктан юлның категориясенә туры килми (норма буенча: П категория - 3 м; III категория - 2 м; IV категория - 1,5 м) | |

| | | |
|---|---|---|
| 2.2 | Юл кырыйлары торышы канәгатьләнерлек түгел: юл кырыеның өслеге юлның машиналар йөрү өлеше өслегеннән 4 см дан күбрәккә түбәнрәк; юл кырыйлары юл өслегенән биегрәк; юл кырыйлары вак таш белән ныгытылмаган һәм анда чыгарга мөмкинлек юк; юл кырыйлары җимерелгән, чокырланган, су тора; юл кырыйларында чит предметлар; юл кырыйларында үлән биеклеге 15 см дан артык | |
| | Ш. Күперләр һәм юлүткәргечләр | |
| 3.1 | Өслек зарарланган, деформацияле, чокырлы, юлның машиналар йөрү өлеше пычрак | |
| 3.2 | Киртәләр булмау (барьерлы, парапетлы, бордюрлы h= 0,75 м); ф = 0,25 м агач күперләрдә тәгәрмәч суккыч юк) | |
| 3.3 | Тротуарлар юк (киңлеге кимендә 0,75 м) | |
| 3.4 | Култыкса киртәләрнең аерым өлешләре зарарлану | |
| 3.5 | Энергия белән тәэмин итү чыганаклары булган очракта күперләр (юлүткәргечләр) яктыртылмау | |
| 3.6 | Күперләргә килү юлында юл билгеләре юк | |
| | IV. Тимер юл кичүләре | |
| 4.1 | Тимер юл кичүләренә килү юлларында юл билгеләре юк | |
| 4.2 | Баганалар, култыксалар, коймалар, шлагбаумнар, билгеләр юк; тротуарлар һ.б. юк яки зарарланган | |
| 4.3 | Тротуарлар юк | |
| 4.4 | Тимер юл кичүләре яктыртылмау (энергия белән тәэмин итү чыганагы булганда) | |
| 4.5 | Тимер юл кичүләре зонасында юлның машиналар йөрү өлеше канәгатьләнерлек түгел (деформацияле, чокырлы, кырыйлары җимерек һ.б.) | |

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| Күтәрелү һәм төшү урыннары булган участоклар | | |
| 5.1 | Биеклеге 2,5 м дан артык булганда киртәләр юк; биеклеге 2 м дан артык булганда сигнал баганалары юк | |
| 5.2 | Күтәрелү (төшү) урыннарында юл билгеләре мәгълүматы юк | |
| VI. Автобус тукталышлары | | |
| 6.1 | Иҗтимагый биналар, дәвалау учреждениеләре, кибетләр һ.б. янында автобус тукталышлары юк; пассажирларны төшерү урыннарында | |
| 6.2 | Тукталышларда тукталыш мәйданчыклары (кереп туктау кесәләре); утырту мәйданчыклары; пассажирлар өчен павильоннар; күчеш-тизлек полосалары (узышу һәм тукталыш мәйданчыгына чыгу өчен) юк. | |
| 6.3 | Тукталыш мәйданчыгының зурлыгы (озынлыгы, киңлеге) нормативларга туры килми: озынлыгы 20 - 30 м һәм киңлеге 3 м | |
| 6.4 | Утырту мәйданчыкларының параметрлары һәм җайланмалары нормативларга туры килми: мәйданчык зурлыгы10 х 3 м; тукталыш мәйданчыгыннан 20 см га өстәрәк | |
| 6.5 | Тукталышлар яктыртылмый (энергия белән тәэмин итү чыганаклары булганда). | |
| VII. Киселешләр һәм кушылмалар | | |
| 7.1 | Төшү (съезд) һәм керү урыннарында өслек озынлыгы юк яки җитәрлек озынлыкта түгел (комлы грунт өчен 9100 м; балчыклы грунт өчен 200 м); сигнал баганалары юк | |
| VIII. Юл билгеләре, юл торышы | | |

| | | |
|---|---|---|
| 8.1 | Юл билгеләре юк яисә аларның күренүчәнлеге тәэмин ителмәгән: уку йортлары зонасында (1.20 - җәяүлеләр кичүе; 2.21 -балалар; 3.24 - максималь тизлекне чикләү; 5.16.1, 5.16.2 җәяүлеләр кичүе); юлның йөрү өлешендә җирле сузылган зонада; хәрәкәт юнәлешләрен, аны тыюны, чикләүне күрсәтә торган; өслек торышын күрсәтә торган; юл эшләре үткәрелә торган зонада | |
| 8.2 | Юл билгеләрендә, киртәләрдә пычрак булу | |
| 8.3 | Мәктәпләр янында, автобус тукталышларында җәяүлеләр кичүе билгеләре юк; юл билгеләре тузган | |
| 8.4 | Торак пунктлар чикләрендәге уку йортлары зонасында тротуарлар, электр уты юк | |
| 8.5 | Юл билгеләре хәрәкәт шартларына туры килми: тизлекне арттыру һәм киметү чикләүләре; юл эшләреннән соң онытылган билгеләр | |

Комиссия бәяләмәсе: Маршрут юл хәрәкәте кагыйдәләре таләпләренә туры килә (туры килми).

Вәкил:

___________________________________________

(орган, вазыйфа, фамилия, исем, атасының исеме, имза)

___________________________________________

(орган, вазыйфа, фамилия, исем, атасының исеме, имза)

___________________________________________

(орган, вазыйфа, фамилия, исем, атасының исеме, имза)